**Татар теле - 21 код**
**8 нче сыйныф I вариант**

| **Эшне башкару өчен күрсәтмә** |
| --- |
| Татар теленнән биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора. Беренче өлеш 15 биремне үз эченә ала (1-15), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган бер җавапны сайлап алырга тиеш. Икенче өлеш 4 биремнән (16-20) тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. Аларга җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез. Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыкса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. |

**1 өлеш**

1. Әлеге билгеләмәгә кайсы **тартык авазы** туры килә: тел арты, яңгырау
1) [г]
2) [к]
3) [д]
4) [з]

2. **Ирен гармониясе** булган очракны билгеләгез.
1) бөтен, болыт, колын
2) бардылар, килде, сорады
3) төньяк, сиңа, фабрика
4) риза, машина, сөлге

3. **[И] сузыгына** дөрес билгеләмәне бирегез.
1) нечкә, иренләшмәгән, кыска сузык аваз
2) калын, иренләшмәгән, озын сузык аваз
3) калын, иренләшкән, озын сузык аваз
4) нечкә, иренләшмәгән, озын сузык аваз

4. **Редукция** – ул
1) авазларның охшашлануы
2) сузыкларның кыскаруы яки төшеп калуы
3) әйтелеше охшаш яки якын булган ике авазадан төрле авазлар барлыкка килү
4) сузык авазларның сүз эчендә бер-берсенә охшашлануы

5. Кайсы төркемдә аваз һәм хәреф саны туры килә?
1) катгый, җәмгыять, гомер
2) гаҗәп, ятим, дәвам
3) ягъни, ябь-яшь, хөкүмәт
4) васыять, Вагыйз, дәва

6. **Кабатланмас** сүзенең дөрес итеп морфемаларга бүленешен күрсәтегез.
1) Кабат-лан-мас
2) Каб-ат-лан-мас
3) Кабат-ла-н-мас
4) Кабатлан-мас

7. **Аша, кебек, саен, кадәр** сүзләре:
1) бәйлек
2) бәйлек сүзләр
3) теркәгечләр
4) хәбәрлек сүзләр

8. Кайсы төркемдә **җыючы теркәгечләр** бирелгән?
1) ягъни, гүя, ки
2) әле-әле, яки, я
3) янә, тагы, вә
4) белән, буенча, өчен

9. Кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга, шулай ук төрле предметлар һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган сүзләр -
1) ымлыклар
2) модаль сүзләр
3) теркәгечләр
4) аваз ияртемнәре

10. **Сәбәп-максат рәвешләре** кайсы рәттә язылган?
1) әрәмгә, юри, бушка
2) бераз, гаять, кичен
3) якын, биектә, берьюлы
4) тиздән, соң, бөтенләй

11. *Айлык хезмәт хакы – егерме биш мең сум.* Бу җөмләдәге сан -
1) чама саны
2) тәртип саны
3) җыю саны
4) микъдар саны

12. **Әйтү максаты ягыннан җөмләнең** төрен бигеләгез: *Тукта!*
1) тойгылы җөмлә
2) боерык җөмлә
3) хикәя җөмлә
4) сорау җөмлә

13**. Җөмләнең төрен** билгеләгез: *Әһә!*
1) исем җөмлә
2) сүз җөмлә
3) фигыль җөмлә
4) ким җөмлә

14. **Җөмләнең төрен** билгеләгез: *Аларны киртә белән әйләндереп алганнар...*
1) бер составлы билгесез үтәүчеле
2) бер составлы билгеле үтәүчеле
3) гомуми үтәүчеле
4) үтәүчесез

15. *Син килүгә мин шатмын. Син килүгә, бу мәсьәләне хәл итәрбез. Син килгәнгә, ул аптырап калды***.** Бу җөмләләрнец мәгънә төрләре буенча урнашу тәртибе түбәндәгечә:
1) вакыт җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә;
2) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә;
3) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, максат җөмлә;
4) тәмамлык җөмлә, күләм җөмлә, сәбәп җөмлә.

## 2 өлеш

| |
|---|
| Әлеге өлештәге биремнәргә җавапны җавап бланкына бирем санынан уң якка беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифрны аерым шакмакка языгыз. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга кирәкми. |

*Бер генә **мәҗлес** тә, бер генә **тантана** да гармуннан башка узмый иде.*

16. Җөмләдәге хәбәрне күрсәтегез.
17. Җөмләдәге синонимнарны табып, күчереп языгыз.
18. Билгеләнгән сүзләр җөмләнең нинди кисәге?
19. **Генә** сүзе кайсы сүз төркеменә карый?
20. **Гармуннан** сүзенең килешен билгеләгез.